**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү
турында

24.03.2024 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 12 мартындагы «2023 елның 21 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 1 санлы, 2023 елның 21 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 2 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында»гы 9 санлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пунктында узган гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «2023 елның 21 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 1 санлы, 2023 елның 21 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 2 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертеп, түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Кәрәкәшле торак пунктында традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалап алу, төзекләндерү (зират территориясендәге коймаларны ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү));

2) тротуарларны төзү, ремонтлау (Мирфәтыйх Зәкиев урамындагы Кәрәкәшле торак пунктында тротуар төзү (смета буенча: вак ком- таш, асфальт сатып алу, нигез әзерләү, ташу, салу, эшләр өчен түләү))

3) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Кәрәкәшле торак пунктында юлларны кардан чистарту, грейдерлау)».

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында Кәрәкәшле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен халыкка җиткерергә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// jutaza.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы ________________ А.Г.Дәүләтгәрәев
(имза)

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы
Для документов
Совет Каракашлинского сельского поселения Ютазинского муниципального района Республики Татарстан